ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына**
**үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2026 елның 22 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 50 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш); 2023, № 48 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 45 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2025, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 74 (I өлеш), № 93; 2026, № 16 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда:

а) 2 өлешнең 15 пунктында «оешмалар» сүзен «Татарстан Республикасында халыкны табигый газ белән тәэмин итүче оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $3^3$ өлеш өстәргә:

«$3^3$. Татарстан Республикасында халыкны табигый газ белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан газ бүлү челтәренең газүткәргечләренә карата, әлеге статьяның 2 өлешендәге 15 пунктында күрсәтелгән мөлкәт объектларыннан тыш, салымның исәпләнгән суммасыннан 72,73 процент күләмендә салым түләнә.»;

2) 5 статьяда:

а) 10 пунктта «2027 елның 1 гыйнварыннан» сүзләрен «2028 елның 1 гыйнварыннан» сүзләренә алмаштырырга;

б) 12 пунктта «2027 елның 1 гыйнварыннан» сүзләрен «2032 елның 1 гыйнварыннан» сүзләренә алмаштырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле 17 пункт өстәргә:

«17) 2032 елның 1 гыйнварыннан әлеге Законның 3 статьясындагы $3^3$ өлешен.».

**2 статья**

Әлеге Закон 2027 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2026 ел, 25 июль
№ 53-ТРЗ